**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 12 октябрь № 740

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче һәм 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче, 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа уналтынчы абзац өстәргә:

«Мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын булдыру, үстерү, яңарту, куллануны күздә тоткан чаралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, яңарту, куллану буенча чараларны координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма

органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, яңарту, куллану буенча чараларны координацияләү турында нигезләмәне исәпкә алып дәүләт программасына кертелә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, яңарту, куллану буенча чараларны координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, яңарту, куллану буенча чараларны координацияләү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 – 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Мәгълүматлаштыру программасы Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен гамәлгә кертү буенча чаралар исемлеген билгеләүче төп норматив хокукый акт булып тора. Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен гамәлгә кертү буенча чаралар алар буенча дәүләт заказчысы итеп мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле орган билгеләнгән очракларда бүтән дәүләт программаларына кертелергә мөмкин.

5. Дәүләт органы үткәрә торган мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, яңарту, куллану буенча чараларны яраштыруны мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле орган Мәгълүматлаштыру программасында яисә Татарстан Республикасында бүтән дәүләт программаларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

6. Гамәлдәге Мәгълүматлаштыру программасына яисә Татарстан Республикасында бүтән дәүләт программасына кертелмәгән мәгълүматлаштыру буенча чара (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүматлаштыру системасын булдыру буенча чара) үткәрү зарурлыгы барлыкка килгән очракта әлеге чараны үткәрүне планлаштырган дәүләт органы мәгълүматлаштыру буенча чара үткәрү өчен нигезне билгели торган һәм әлеге чараны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентында билгеләнгән тәртиптә Мәгълүматлаштыру программасына яисә Татарстан Республикасында бүтән дәүләт программасына кертү турында нигезләмәне үз эченә алган норматив хокукый акт проектын эшли һәм мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле органга килештерү өчен җибәрә.»;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Мәгълүматлаштыру буенча чараларны үтәүне мониторинглауны мәгълүматлаштыру буенча вәкаләтле орган функциональ операторлар – дәүләт

мәгълүмат системасын файдалану буенча, шул исәптән мәгълүматлар базасындагы мәгълүматны эшкәртү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган дәүләт органнары, алар вәкаләтләр биргән бюджет учреждениеләре белән берлектә гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\740.docx